ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                        КАРАР

________________          с. Верхний Услон          ________________

2025 елда Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территорияләренә «Иннополис мәктәбе» ДАМУ беркетү турында

"Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 67 статьясындагы 3 өлеше, РФ Мәгариф министрлыгының "Мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программалары буенча укырга кабул итү тәртибен раслау турында" 2020 елның 15 маендагы 236 номерлы боерыгы нигезендә, мәктәпкәчә белем бирүнең мөмкинлеге гарантияләрен тәэмин итү максатларында, "Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге территорияләрендә 2025 елда мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем алуга гражданнарны кабул итү өчен «Иннополис мәктәбе» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесен (1-нче кушымта) беркетергә.
2. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесенә әлеге карарны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис мәктәбе» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесе игътибарына җиткерергә.
3. «Иннополис мәктәбе» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесенә балаларны кабул иткәндә әлеге карар белән эш итәргә.
4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесенең рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Иннополис мәктәбе» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесе сайтында урнаштырырга.

Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе башлыгына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы А. А. Ахметшин

Әзерләде һәм бастырды
Ф.М. Әхмәтова, 3 нөсхәдә.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль
районы Башкарма комитетының
2025 ел _____ №_________
Карары белән расланган
1 номерлы кушымта

2025 елда Югары Ослан муниципаль районы территорияләрендә гражданнарны башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итү өчен беркетү

| № | Мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениесе исеме | Шәһәр җирлеге территориясендә урнашкан ныгытылган торак пунктлар |
|---|---|---|
| 1. | «Иннополис мәктәбе» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесе | Иннополис шәһәре |